# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге составына керүче Яңа Оча торак пунктында 2024 елга үзарасалым кертү турында

№ 3 15 ноябрь 2023 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 5 нчыстатьялары, «Татарстан Республикасындаҗирле үзидарә турында»гы 200 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 3 нчестатьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбә Тәкәнеш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясынигезенд Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авы җирлегенең Яңа Оча торак пунктында узган гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авы җирлегенең Яңа Оча торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгә балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм сугы хәрәкәтләре ветераннары, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларны гаилә әгъзалары (хатыны һәм 18 яшькә кадәрге балалары), көндезге бүлектә беле алучы студентлар, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәт итүгә чакырылга гражданнар кала, 2024 елда 500(биш йөз) сум күләмендә үзарасалым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндә эшләрне башкаруга тотарга:

- Яңа Оча торак пунктында Октябрь урамы юлны вакташ җәеп ремонтла (материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Яңа Оча торак пунктындагы җирле әһәмиятле юлларны кардан чистарту һә грейдер белән тигезләү (килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Яңа Оча торак пунктында урамнарны яктырту объектларына хезмәт күрсә (агымдагы ремонт, урам яктырткычларының лампочкаларын алыштыру, килеш буенча эшләр өчен түләү).

3.Әлеге карарны Түбән Тәкәнеш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарста Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыр юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,<br>
Мамадыш муниципаль районы<br>
Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге Башлыгы,<br>
Совет рәисе Р.Җ.Хәмизуллин